КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 март г.Казань № 197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсуслашкан торак фондта яшәүче ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларны озата бару турында» 2017 ел, 21 март, 169 нчы карарына, преамбуладагы «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын» сүзләрен «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар социаль наем шартнамәләре буенча наемга алучылар яки наемга алучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләр булган торак урыннарның кулланылышын һәм сакланышын, торак урыннарның тиешле санитар һәм техник хәлен тәэмин итүне, алар белән эш итүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 апрель, 374 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның

торак урынына хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар социаль наем шартнамәләре буенча наемга алучылар яки наемга алучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләр булган торак урыннарның кулланылышын һәм сакланышын, торак урыннарның тиешле санитар һәм техник хәлен тәэмин итүне, алар белән эш итүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибенең 1.1 пунктында «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин